ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
СТАРОСЛЯКОВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АГРЫЗСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘГЕРҖЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЭСЛӘК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.03.2024 Иске Эсләк авылы № 13

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетында эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 23.01.2023 елның 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 02 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге башкарма комитетында эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләрен раслау турында» 23.01.2023 елның 1 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 бүлекнең 3.2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 32 пунктча өстәргә:

«32) яллаучы вәкиленә (эш бирүчегә) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетадагы мәгълүм үзгәрешләр турында аңа мәгълүм булган мәгълүматлар турында язма рәвештә хәбәр итәргә, моңа яллаучы (эш бирүче) вәкиленең карары буенча үзгәргән белешмәләр керми.»;

2) 2 бүлекнең 2.3 пунктындагы 2 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_2 статьясында каралган анкетаны;»;

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының веб-адрес буенча портал составында урнаштырырга: https://agryz.tatarstan.ru, шулай ук Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Иске Эсләк авыл җирлеге җирле үзидарә органнары территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкчесе Д.М.Әхмәтов